


# Әхмәтҗанов Рәшит Хәнип улы



Әхмәтҗанов Рәшит Хәнип улы

(14.04.1941-5.01.1995)
Рәшит Әхмәтҗанов 1941 елның 14 апрелендә Баулы районы Татар Кандызы авылында колхозчы гаиләсендә туган.

- Авыл мәктәбендә җиде сыйныф белем алганнан соң, 1957 - 1958 нче елларда Бөгелмәдә төзүчеләр әзерләү училищесында укый, аны тәмамлагач, нефть районнарында һәм Әлмәт шәһәрендәге төзү оешмаларында ташчы булып эшли. 1961 - 64 нче елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. Армиядән кайткач, В.И. Ульянов - Ленин исемендәге Казан Дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кереп, 1969 нчы елда аны тәмамлап чыга һәм 1980 нче елга кадәр башта Татарстан культура министрлыгында сәнгать эшләре буенча инспектор, аннары "Яшь ленинчы" һәм "Татарстан яшьләре" газеталарында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1980 елдан ул "Казан утлары" журналы редакциясе хезмәткәре иде.

